**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево Азнакаевского муниципального района 423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл жирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы, Молодежный урамы, 1а 423302, Тел. (8-292) 4-47-23

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «30» гыйнварь 2026 № 1

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында»гы 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында»гы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, 2026 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 9 678,63 (тугыз мең алты йөз житмеш сигез сум алтмыш өч тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Башкарма комитетының «2025 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясенең иң чик күләмен раслау турында» 30.01.2025 № 1 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис Л.Л.Хәбипов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтачавыл җирлеге Башкарма комитеты карарына №1 нче кушымта
«30» гыйнварь 2026 № 1

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
«Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 200,00 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2000,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **4** | **Барлыгы** | **9 678,63** |

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районының  Балтач авыл
җирлеге Башкарма комитеты карарына
№2 нче кушымта
«30» гыйнварь 2026 № 1

2026 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының
«Балтач авыл җирлеге»  муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге
бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1 600,00 |
| 2 | Мәетне җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 600,00 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 2000,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 478,63 |
| **5** | **Барлыгы** | **9 678,63** |